# ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАР НӘТИҖӘЛӘРЕ
# ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘ

2019 елның «30» апреле Зеленодольск шәһәре

Зеленодольск шәһәре Мэрының 2019 елның 15 апрелендәге 02-03-07 номерлы карары белән «2018 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Зеленодольск шәһәре Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләнгән. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты (http://zelenodolsk. tatarstan.ru) Гавами тыңлаулар 2019 елның 30 апрелендә Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 46нчы йорт адресы буенча, Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәгендә үткәрелде.

Гавами тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә - Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Зеленодольск шәһәре Советының 2018 елгы карар проекты.

Гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы - Зеленодольск шәһәре Мэры.

Гавами тыңлаулар уздыру датасы, вакыты һәм урыны- 2019 елның 30 апреле,15.00, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 46нчы йорт адресы буенча, Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәге.

Гавами тыңлаулар уздырган оештыру комитеты:

1. Гарипов А.Ш. - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;
2. Дёгтева О.П. - «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесе;
3. Стерякова А.С. - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализ бүлеге башлыгы;
4. Ассельборн С.А. - Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы бюджетлары белән үзара мөнәсәбәтләр бүлеге башлыгы;
5. Соловьев А.В. - Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре буенча Зеленодольск шәһәре Советының даими комиссиясе рәисе.

Гавами тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән чыгышка хокук алган затлар турында мәгълүмат: докладчылар, оештыру комитеты әгъзалары, Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләре, шәһәр һәм Зеленодольск муниципаль районы халкы катнашты.

Мәсьәләне хәл итү буенча рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр кермәде.

Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең йомгаклау варианты үзгәрешсез кабул ителде.

Гавами тыңлауларда катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре:

14 (кеше) риза

0 (кеше) каршы.

0 (кеше) тыелып калды

Оештыру комитеты рәисе А.Ш. Гарипов

Оештыру комитеты секретаре С.А. Ассельборн